ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОАКСУБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АКСУБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д.31,
с.Новое Аксубаево, 423070

Үзек урам,31 енче йорт
Яңа Аксубай авылы , 423070

Тел.: (84344) 4-20-47, факс: (84344) 4-20-47. E-mail:Naks.Aks@tatar.ru , http://aksubayevo.tatarstan.ru

# КАРАР

№ 1 29.01.2025 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2025 елга мәет җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге хакының иң чик күләмен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» № 33 23.01.2025 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2025 елның 1 февраленнән 9165,37 (Тугыз мең йөз алтмыш биш сум, 37 тиен) күләмендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Үз көчен югалткан дип таныргa:

- “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гарантияләнгән хезмәт күрсәтүләр исемлегенең иң чик күләмен раслау турында” Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының 2025 елның 1 февраленнән.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге веб-адрес буенча рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Яңа Аксубай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: А.В.Макаров

кушымта   № 1
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма
комитеты карарына
« 29» гыйнвар 2025ел № 1

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2025 елга мәет җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең иң чик хакының күләме

| **Хезмәтләрнең аталышы** | **Хезмәтләрнең бәясе ( сум)** |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4566,37 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратта күчерү | 1095 |
| 4. Кабер казу һәм күмү | 3504 |
| **Барлыгы** | **9165,37** |

кушымта   № 2
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитеты карарына
« 29» гыйнвар 2025ел № 1

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 01.02.2025 елдан җирләү буенча гарантияле хезмәтләр бәясе исемлеге.

| **Хезмәтләрнең аталышы** | **Хезмәтләрнең бәясе ( сум)** |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне тәртипкә китерү,киендерү | 547,50 |
| 3.Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4018,87 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратта күчерү | 1095 |
| 5. Кабер казу һәм күмү | 3504 |
| **Барлыгы** | **9165,37** |